***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Саңгырау тартык авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *боз*
   **ә) *кар***
   б) *яңгыр*
   в) *җил*

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *ботка*
   ә) *кашык*
   **б) *тәлинкә***
   в) *кайнатма*

3. Парсыз саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ч]
   ә) [в]
   б) [й]
   **в) [х]**

4. “***Сөйләшмиләр***” сүзендәге басымлы иҗекне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) 1 нче иҗек
   **ә) 2 нче иҗек**
   б) 3 нче иҗек
   в) 4 нче иҗек

5. Күчерелмә мәгънәдәге сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *йомшак сүз***
   ә) *йомшак мендәр*
   б) *йомшак урындык*
   в) *йомшак күмәч*

6. Тамырдаш сүзләрдән торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *чиләк, чирәм*

ә) *боз, ботка*
б) *бал, балчык*
**в) *күз, күзлек***

7. Исемне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) *баш***
ә) *башлый*
б) *башлы*
в) *без*

8. Хәзерге заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *укы*
**ә) *укый***
б) *укыды*
в) *укыр*

9. Нокталар урынына куела торган кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**
*Чебен**...** фил ясау.* (Мәкаль)
а) -*гә*
ә) -*дән*
**б) *-нән***
в) -*не*

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *Мин урамга чыктым.*
ә) *Әкрен генә йомшак кар ява.*
б) *Балалар кар бабай ясыйлар.*
**в) *Көн салкын түгел.***

## II. Башыгызны эшләтегез.

*Алма агачыннан ерак төшми. Бүредән курыккан урманга бармас.* **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне, авазларны һәм кушымчаларны өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Табигать сүзендә **сигез** хәреф, **җиде** аваз бар. Әлеге сүздәге сузык авазлар: [**а**], [**и**], [**ә**]. ь – **аваз** белдерми. Табигать - **исем** сүз төркеме, ясалышы ягыннан **тамыр** сүз. Табигать сүзе урын-вакыт килешендә килгәндә, аңа **-тә** кушымчасы ялгана. Табигать сүзенең мәгънәсен **аңлатмалы** сүзлектән белеп була.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

Мәсәлән: *Минем апам/сеңелем бу шигырьне ятлый/хәтерендә калдыра алмый.*

*Язучы бик күп китап язды/язган.*
*Мин сезнең белән паркка бара алмый.*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

*Бер кешене**ң** ике улы булган. Әтиләре базардан икесенә дә берәр алма алып кайткан. Алмалар бик п**е**шкән, татлы, сус**ы**л иде.*

*Өлкән улы алманы ашый, орл**ы**кларын җыеп куя. Бакчага чәч**е**п, алма агачы ут**ы**ртырга тели.*

*Төпч**е**к улы үзенең алмасын а**в**ырып яткан күрше егетенә бирә.* (Дәрдемәндтән)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(2 балл)**
*пешкән* – **өлгергән**, *татлы* – **баллы**
2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(2 балл)**
*чәчә* – **җыя**, *егет* – **кыз**
2.3. Алма нинди була? 10 сыйфат языгыз. **(5 балл)**
Мәсәлән: **түгәрәк, зур, кечкенә, сусыл, кызыл, сары, яшел, баллы, әче, файдалы**

3. Үзегез яратып ашый торган җиләк-җимеш яисә яшелчә турында 5 җөмлә төзеп языгыз. **(5 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Яңгырау тартык авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *такта*
   ә) *чүп*
   б) *сөт*
   **в) *өстәл***

2. Калын сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *гөбәдия*
   **ә) *кыстыбый***
   б) *бәлеш*
   в) *пәрәмәч*

3. Парлы саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) [ф]**
   ә) [х]
   б) [һ]
   в) [щ]

4. “*Аңламады”* сүзендәге басымлы иҗекне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) 1 нче иҗек
   **ә) 2 нче иҗек**
   б) 3 нче иҗек
   в) 4 нче иҗек

5. Күчерелмә мәгънәдәге сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *җылы күлмәк*
   ә) *җылы көн*
   б) *җылы бүлмә*
   **в) *җылы караш***

6. Тамырдаш сүзләрдән торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *бит, битлек***
   ә) *күл, күлмәк*

б) *биш, бишек*
в) *җил, җимлек*

7. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) *яшел*
**ә) *яшькелт***
б) *ямь-яшел*
в) *яшелрәк*

8. Тартым алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
а) *мин*
**ә) *синеке***
б) *бу*
в) *кем*

9. Нокталар урынына куела торган кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**
*Бер тамчы**...** диңгез булмый.* (Мәкаль)
а) -*да*
ә) -*нан*
**б) -*дан***
в) -*ның*

10. Раслау җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *Мин китап укымадым.*
ә) *Алсуның дәфтәре юк.*
б) *Бу алма баллы түгел.*
**в) *Бүген урамда кар ява.***

## II. Башыгызны эшләтегез.

*Караңгы төндә йолдызлар яхшырак яна. Кышка каршы тиен дә байлык җыя.* **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне, авазларны һәм кушымчаларны өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Юлдаш сүзендә **биш** хәреф, **алты** аваз бар. Әлеге сүздәге тартык авазлар: [**й**], [**л**],[**д**], [**ш**]. Юлдаш – **исем** сүз төркеме, ясалышы ягыннан **ясалма** сүз. Юлдашым сүзе **тартым** белән төрләнгән. Юлдаш сүзенең мәгънәсен **аңлатмалы** сүзлектән белеп була.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**
Мәсәлән: *Җәй көне диңгездә ничек рәхәт!*

*Яңгырдан соң балалар салават күперен/салават күпере чыкканын көттеләр.*

*Бу йортны инде бик озак төзиләр.*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

*Тәрбияле бала ч**ә**йне яхшы гына утырып **э**чәр, икмәкне дә к**а**дерләп кенә ашар. Аяк өст**е**ндә ашап **й**өргән кешенең икмәк **в**алчыклары, җиргә төш**е**п, аяк белән тапталыр. Шуңа күрә тәрбияле бала **һ**ичбер вакытта баскан килеш ашамас.* (Ризаэддин Фәхреддин)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(3 балл)**

*бала* – **сабый**, *тәрбияле* – **тәртипле**, *кешенең* – **адәмнең**

2.2. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(3 балл)**

*аяк* – **кул**, *эчәр* – **ашар**, *өстендә* – ***астында***

2.3. Текстта кулланылган кушма сүзне табып языгыз. **(1 балл)** **(һичбер)**

2.4. Текстта кулланылган тартым белән төрләнгән исемне табып языгыз. **(1 балл) (валчыклары)**

3. Тырыш укучы нинди була? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 56**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Иренләшкән сузык авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *мәктәп*
   ә) *сыйныф*
   б) *дәрес*
   **в) *акбур***

2. [w] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *чәүкә***
   ә) *күке*
   б) *үрдәк*
   в) *тукран*

3. Юлдан-юлга күчереп булмый торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *түшәм*
   **ә) *идән***
   б) *кием*
   в) *яулык*

4. ***Былтыр*** сүзенең синонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *быел*
   ә) *киләсе ел*
   **б) *узган ел***
   в) *кичә*

5. *Рус* алынмасын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *базар*
   **ә) *өстәл***
   б) *китап*
   в) *хат*

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *озын(борын)***
   ә) *әкәм(төкәм)*
   б) *дус(иш)*

в) *кура(җиләге)*

7. Ноктalar урынына куела торган кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**

*Су башын**...** болгана.* (Мәкаль)

а) -*да*

**ә) *-нан***

б) -*дан*

в) -*ның*

8. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кызыл*

ә) *кызылрак*

**б) *җете кызыл***

в) *кызгылт*

9. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *син*

ә) *безнеке*

**б) *шул***

в) *кайда*

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Юл буенда агач үсә.*

ә) *Тиздән Яңа ел җитә.*

б) *Мин бию түгәрәгенә йөрим.*

**в) *Безнең сыйныфта укучылар күп түгел.***

## II. Башыгызны эшләтегез.

Ашыккан су диңгезгә җитмәс. Тирән күлдә балык та күбрәк. **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне һәм авазларны өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Уен-көлке сүзендә **сигез** хәреф, **тугыз** аваз бар, анда **дүрт** сузык аваз, **биш** тартык аваз. Уен-көлке – **исем** сүз төркеме, ясалышы ягыннан **парлы** сүз. Сүзнең тамырлары – **уен** һәм **көл** . Нигезе – **уен-көлке**. Уен-көлке сүзенең мәгънәсен **аңлатмалы** сүзлектән белеп була.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*Мондый яңгырлы көндә өйдә утыру яхшырак.*

*Ул бик оялчан. Аның дус кызлары бик аз.*

*Минем бу мәсьәләгә караган берничә китабым бар.*

*Автобуста кеше артык күп иде.*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

*Элекке заманда ике иптәш юлга ч**ы**кканнар. Боларга зур урман аркылы үтәргә туры килгән. Урманга к**е**ргәннәр икән, боларның каршысына кинәт кенә бер аю килеп чыккан. Мон**ы** күргәч, боларның берсе, бик куркып, агач башына м**е**неп качкан. Икенчесе, үлгән булып, тиз генә с**у**зылып яткан.*

*Аю, бу юлда яткан кешенең яны**н**да әйләнә-әйләнә, башларын, аякларын **и**снәгән дә, ди, бер дә т**и**мичә, үз юлына киткән, ди.* (Татар халык әкияте)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(3 балл)**

*элекке* – **әвәлге**, *аркылы* – **аша**, *каршысына* – **алдына**

2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(3 балл)**

*зур* – **кечкенә**, *иптәш* – **дошман**, *тиз* – ***әкрен***

2.3. *Урманга* сүзенең транскрипциясен языгыз. [**урмаңға**] **(2 балл)**

3. Әйбәт иптәш, дус нинди була? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 64**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. [w] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *телевизор*
   ә) *юкә*
   **б) *дәүләт***
   в) *үлән*

2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *барам*
   **ә) *барабыз***
   б) *бардык*
   в) *бардылар*

3. Рус алынмасын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *алгебра*
   **ә) *мунчала***
   б) *һәйкәл*
   в) *йорт*

4. ***Элек*** сүзенең синонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *тиздән*
   ә) *бүген*
   б) *быел*
   **в) *әүвәл***

5. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *мал(туар)***
   ә) *баш(кала)*
   б) *бака(яфрагы)*
   в) *драм(түгәрәк)*

6. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *соры*
   ә) *сорырак*

б) *соп-соры*
**в) *соргылт***

7. Билгеләү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
а) *алар*
**ә) *һәрчак***
б) *кемдер*
в) *шушы*

8. Саф рәвешне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) *җәяү***
ә) *ерак*
б) *элек*
в) *күп*

9. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *килде*
ә) *килгән*
б) *киләчәк*
**в) *килер***

10. Җәенке җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *Кыш.*
ә) *Туңдырды.*
б) *Кар ява.*
**в) *Йомшак кар ява.***

## II. Башыгызны эшләтегез.

Читлеккә өйрәнгән кош иректә башын югалтыр. Карчыга авызыннан ит кире чыкмый. **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Явым-төшем сүзендә* ***дүрт*** *сузык аваз,* ***алты*** *тартык аваз бар. Ул сингармонизм законының рәт һәм* ***ирен*** *гармониясенә буйсынган. Сүз басымы* ***беренче*** *компонентның* ***икенче/соңгы*** *иҗегенә төшә. Явым-төшем –* ***исем*** *сүз төркеме, ясалышы ягыннан* ***парлы*** *сүз. Сүзнең тамырлары –* ***яу(в)*** *һәм* ***төш****. Явым-төшем сүзеннән -сез кушымчасы ярдәмендә* ***сыйфат*** *сүз төркеме ясала ала.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

Мәсәлән: *Сез үз үзегезне кулга алырга тиешсез.*
*Гадәттә ул мәктәпткә җәяү йөри.*
*Кичен алар өйнең астын өскә китерделәр, ләкин китапны тапмадылар.*

*Мин балачакта балетта биергә хыялланган идем.*

2. Төшеп калган кушымчаларны һәм сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

*Бердән**бер** көнне Карга Күке белән очрашкан. Алар бер-берсе**нең** хәл-**әхвәлен** сорашканнар. Күке, Карга белән хушлашып, үз юлына китә. **Очып** барып, бер агачка куна да, бик матур итеп:*

- *Күк-ке, күк-ке, - дип кычкыра башлый.*

*Карга моны ишетеп көнләшеп куя.*

- *Мин Күке кебек үз исемемне әйтеп бетерә алмам**мыни**? Минем тавышым да көр, сыным да матур, - ди ул.*

*Шуннан **соң** Карга: "Кар-га, Кар-га", - дип кычкырып йөри башлый.*

*Бервакыт Карга, азык **эзләп** йөргәндә, бер Тургайны эләктереп ала да авызына каба. Шулчак Тургай Каргадан:*

- *Агай, синең исемеңне беләсем килә. Син миңа үз исемеңне әйтә күр инде, - дип үтенгән.*

- *Кар-га, Кар-га, - дип кычкырган Карга. Тургай Карга авызыннан **очып** чыгып та китә. Карга үз исемен әйткәнгә бик үкенгән. Шуннан соң ул үз исемен бервакытта да тулысынча әйтми, "Карр, карр", - дип кенә кычкыра икән.* (Башкорт халык әкияте)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(3 балл)**

*хушлашып* – **саубуллашып**, *сыным* – **гәүдәм**, *эләктереп* – **тотып**

2.2. *Үкенгән* сүзенең транскрипциясен языгыз. [**үкэңгән**] **(2 балл)**

2.3. Кушма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз. (**бердәнбер, бервакыт, бервакытта**). **(3 балл)**

3. Сезнең исемегез нинди мәгънә аңлата? Ни өчен сезгә әти-әниегез шундый исем кушкан? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 66**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. [э] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *ел*
   **ә) *тел***
   б) *көчек*
   в) *елга*

2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *йөгерә*
   ә) *йөгердек*
   **б) *йөгерәләр***
   в) *йөгерделәр*

3. Рус алынмасын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *опера*
   ә) *фигыль*
   б) *яңгыр*
   **в) *кәбестә***

4. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Сабак бирү***
   **а) *орышу***
   ә) *укыту*
   б) *мактау*
   в) *курку*

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *кара(бөрлегән)*
   ә) *иртә(кич)*
   б) *ал(су)*
   **в) *тере(көмеш)***

6. Юклык алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *кайда*
   ә) *андый*

**б) *һичкем***
в) *әллә кая*

7. Затланышлы фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
**ә) шарт фигыль**
а) хәл фигыль
б) сыйфат фигыль
в) инфинитив

8. Ияртүче теркәгечне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *ләкин*
ә) *һәм*
**б) *чөнки***
в) *яки*

9. Сүзтезмәне билгеләгез. (**2 балл)**
а) *кар*
**ә) *ап-ак кар***
б) *кар, буран*
в) *Кар ява.*

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Әнкәм йорты – алтын бишек.* (Мәкаль)
а) *әнкәм*
**ә) *йорты***
б) *алтын*
в) *бишек*

**II. Башыгызны эшләтегез.**

Үзең ишетәсе килмәгән сүзне кешегә сөйләмә. Караңгы йөздән тәмле сүз чыкмас. **(4 балл)**

**III. Теоретик бирем.**

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Гыйлем сүзендә **ике** сузык аваз, **өч** тартык аваз бар. Ул сингармонизм законының рәт гармониясенә **буйсынган**. **Ике** иҗектән тора. Аңа **нечкә** кушымча ялгана. Ул – **гарәп/гарәп-фарсы** алынмасы. Белем – аның **синонимы**. Гыйлем – **исем** сүз төркеме. Гыйлем сүзеннән -ле һәм -сез кушымчалары ярдәмендә **сыйфат** сүз төркеме ясала ала. Галимне гыйлем **иясе** диләр.*

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**
Мәсәлән: *Кыш кинәт авыл халкы көтмәгәндә килеп җитте/башланды.*
*Урман кырыенда/читендә агач йорт тора.*

*Елгаларда, күлләрдә, буаларда бик күп балык бар.*

*Карлыгачлар, сыерчыклар, кара каргалар, торналар инде җылы якка очып киттеләр.*

2. Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

*Зөлфиянең әнисенә бүләккә дип ясаган рәсеме, чыннан да, искиткеч матур чыккан иде. Бөтен дәфтәр битен алып торган гөлчәчәк рәсеме ясады ул. Чәчәк* ***таҗына*** *сары сандугач баласы кунган. Һавада ак* ***болытлар*** *йөзә. Алар арасыннан кояш алтын* ***нурларын*** *сибә. Ә сандугач, шул* ***нурларда*** *коена-коена, рәхәтләнеп сайрый.*

*Бүген бу рәсемне Актәпи ерткан. Яңа рәсем ясарга вакыт калмады.*

*Бөтен кеше әнисен котлый,* ***бүләк*** *бирә башлады. Әтисе Зөлфиянең хәлен аңлады.*

*– Ә син, кызым, әниеңә бер матур көй* ***уйна****, – диде ул. Пианиноның* ***капкачын*** *ачты.*

*Зөлфия әкрен генә пианино телләренә басты. Көй бетүгә, барысы да шаулатып* ***кул*** *чаптылар.*

*– Рәхмәт сиңа, кызым! – дип кочаклап үпте әнисе Зөлфияне. – Синең бу бүләгең – миңа иң кадерле, иң кыйммәтле бүләк.* (Габделхәй Сабитовтан)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(2 балл)**

*һавада* – **күктә**, *сандугач* – **былбыл**

2.2. *Кунган* сүзенең транскрипциясен языгыз. **(2 балл)** [**қуңған**]

2.3. Кушма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз. **(4 балл)** (**искиткеч**, **гөлчәчәк, бүген, Актәпи**)

3. Сезнең өчен иң кадерле бүләк нинди? Яңа елга әти-әниегезгә, туганнарыгызга нинди бүләк әзерлисез? Шул хакта 8 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Тел арты ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *әнкәй***
   ә) *әткәй*
   б) *урамнар*
   в) *карга*

2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *йоклый*
   **ә) *йоклыйбыз***
   б) *йоклаган*
   в) *йоклаганнар*

3. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Ике адым***
   **а) *якын***
   ә) *ерак*
   б) *тиз*
   в) *аз*

4. Тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *ак(кош)*
   ә) *тоз(сыз)*
   **б) *кура(җиләге)***
   в) *тирә(як)*

5. Чама санын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *биш бөтен уннан өч*
   ә) *икешәр*
   б) *унау*
   **в) *егермеләп***

6. Икеләнүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) -*мы*

**ә) *-дыр***
б) *-чы*
в) *гына*

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*__Ялкауның__ көн дә башы авырта.* (Мәкаль)
**а) аергыч**
ә) тәмамлык
б) ия
в) урын хәле

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Оятсыз кеше өчен оятлының йөзе кызарыр.* (Мәкаль)
а) *оятсыз*
ә) *кеше*
б) *оятлының*
**в) *йөзе***

9. Гади җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *Ачу килсә, акыл китәр.* (Мәкаль)
ә) *Аю – көченә, кеше акылына ышана.* (Мәкаль)
**б) *Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.* (Мәкаль)**
в) *Акыллы ерып чыга алмаслык эш дөньяда юк.* (Мәкаль)

10. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *Кеше акылын ишет, үзеңнеке белән эш ит.* (Мәкаль)
**ә) *Бит күрке – күз, тел күрке – сүз.* (Мәкаль)**
б) *Үз акылың җитмәсә, кешене тыңла.* (Мәкаль)
в) *Җәяүлегә янчык та авыр.* (Мәкаль)

## II. Башыгызны эшләтегез.

Ахмак төйнәгән төенне акыллы да чишә алмас. Тинтәкнең акылы төштән соң төшәр. **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Мәкаль сүзендә **ике** сузык аваз, **өч** тартык аваз бар. Ул сингармонизм законының рәт гармониясенә **буйсынган**. **Ике** иҗектән тора. Аңа **нечкә** кушымча ялгана. Ул – **гарәп/гарәп-фарсы** алынмасы. Мәкаль-**әйтем** – парлы сүз. Мәкаль – **исем** сүз төркеме. Мәкаль сүзеннән **мәкальләшү** фигыле ясалган. Мәкальләр җыючыны, аларны өйрәнүчене **мәкальче** диләр.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

Мәсәлән: *Яңгыр әле туктамады, ә су тамчылары агачтан төшәләр һәм кояшта җемелдиләр.*

*Мин үзебезнең балык тотуыбыз турында мавыгып сөйләдем.*

*Кич белән без бик зур имән үскән аланлыкка чыктык.*

*Әгәр җил тынса, без чәчәкләр утыртырбыз.*

2. Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

*(1) Без Илсөяр белән чишмә буена йөгердек. (2)Нәрсә бу? (3)Чишмәнең җырлый-җырлый челтерәве* ***ишетелми****. (4)Үзе дә* ***күренми****. (5)Аның өсте кызыл* ***балчык*** *белән <u>капланган</u>.*

*(6)Илсөяр дә, мин дә, чырылдап, яңадан тау <u>итәгенә</u> йөгердек. Бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә:*

*– Әби! Чишмә... юк! Үлгән! – дигәч, Бибинур әби куркып ук калды.*

*– Кайсының кулы барды икән?! – дип, кәрҗинен кулыннан* ***төшереп*** *җибәрде.*

*Без Бибинур әби артыннан атладык. Бибинур әби килә-килешенә күлмәк* ***итәкләрен*** *биленә кыстырып куйды да* ***эшкә*** *тотынды. Аннан күреп, без дә кул белән балчык "көри" башладык.*

*Тиздән чишмәбез терелде: элеккечә җырларга* ***тотынды****, чип-чиста булып ага башлады. Без Илсөяр белән, кушучлап, чишмә авызына үрелдек.*

*Җир йөзендә яхшылыклар да, яманлыклар да җитәрлек шул. Туган туфрагын яратмаган кешедән нинди игелек көтмәк* ***кирәк****.* (Айгөл Әхмәтгалиевадан)

2.1. Беренче абзацтагы тел арты ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзнең астына сызыгыз. **(1 балл)**

2.2. 6 нчы җөмләдәге күчерелмә мәгънәле сүзнең астына сызыгыз. **(1 балл)**

2.3. Текстта кулланылган рус алынмасын языгыз. **(1 балл) кәрҗин**

2.4. Кушма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз. **(3 балл)** (**Илсөяр**, **Бибинур, кушучлап**)

3. Сез табигатьне ничек саклыйсыз? Чишмәләрне саклау нәрсәгә кирәк? Шул хакта 10 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Ирен гармониясе чагылыш тапкан сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *кош*
   ә) *бозлавык*
   б) *шугалак*
   **в) *соргылт***

2. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Теш кайрау***
   а) *ачулану*
   **ә) *янау***
   б) *ярату*
   в) *мактау*

3. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *балта*
   ә) *балчык*
   **б) *баллы***
   в) *балкый*

4. Микъдар санын билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *дүрт бөтен уннан бер***
   ә) *дүртәү*
   б) *дүртенче*
   в) *дүрт-биш*

5. Көчәйтүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *дөм***
   ә) *әллә*
   б) *бит*
   в) *түгел*

6. Хәбәрлек сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *әмма*

ә) *ой*
б) *саен*
**в) *юк***

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәгенә икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Начарны **күрмәгән** – яхшының кадерен белмәс.* (Мәкаль)
а) хәбәр
**ә) ия**
б) аергыч
в) тәмамлык

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Алтыда белгән ана телен алтмышта онытмас.* (Мәкаль)
а) инкяр, боеру җөмлә
ә) раслау, хикәя җөмлә
**б) инкяр, хикәя җөмлә**
в) раслау, сорау җөмлә

9. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бал тамган телдән агу да тамар.* (Мәкаль)
а) гади җөмлә
ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
**в) иярченле кушма җөмлә**

10. Җөмләдәге иярчен компонентның төзелеше һәм мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Үзең алтын булмасаң да, сүзең алтын булсын.* (Мәкаль)
**а) синтетик кире шарт җөмлә**
ә) синтетик шарт җөмлә
б) аналитик шарт җөмлә
в) синтетик рәвеш җөмлә

## II. Башыгызны эшләтегез.

*Бер егетнең кыюлыгы мең егеткә дан китерә. Кыюсыз йөрәк теләген теләп кенә калыр.* **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Мөгаллим сүзендә өч сузык аваз, **биш** тартык аваз бар. Сузык авазлары: [ө], [ә], [и]. Ул сингармонизм законының рәт гармониясенә **буйсынган**. **Өч** иҗектән тора. Аңа **нечкә** кушымча ялгана. Ул – **гарәп/гарәп-фарсы** алынмасы. Синонимы – **укытучы**. Мөгаллим – **исем** сүз төркеме.*

*Хатын-кыз мөгаллим – **мөгаллимә** дула. Мөгаллим сүзеннән **мөгаллимлек** исеме ясалган.*

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

Мәсәлән: *Поезд зур тизлек белән бара башлады, аның утлары караңгылык эчендә юкка чыктылар/югалдылар.*

*Тычкан йөгерде, койрыгын селкеп җибәрде, йомырка ватылды.*

*Мин күк/һава белән диңгез кушылган/тоташкан якка карадым/ күз ташладым.*

*Ул иптәшләренең аңа булышуын/ярдәм итүен тели.*

2. Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

*Урманны **кем** генә яратмый икән? Мөгаен, андый кеше **юктыр**! Ә шагыйрьләр, язучылар өчен урман – **илһам*** чыганагы*. Габдулла Тукайның* ***Кырлай*** *урманнары турында язганнары һәммәбезнең **хәтерендә*** саклана*. **Без** дә урманны бик яратабыз. Аның гүзәллеген, ямен мактарга матур сүзләр эзлибез.*

*Матурлыгы, табигатькә ямь бирүе **өстенә**, урманның файдасы да бик күп. Ул без сулый торган **һаваны** сафландыра, тузаннан чистарта, шуңа күрә дә урманның һавасы һәрвакыт саф була.*

*Матур да, файдалы да урман! Аны сакларга кирәк! Урман һавасына ни җитә?!* (Көндәлек матбугаттан)

2.1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең астына сызыгыз. **(4 балл)**
2.2. Икенча абзацта кулланылган рус алынмасын языгыз. **(2 балл) чистарта**
2.3. Кушма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз. **(2 балл)** **(һәммәбезнең, һәрвакыт )**

3. Урманның матурлыгын һәм файдасын сурәтләп, 12 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2022-2023 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Рәт гармониясенә бусынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *шигырь*
   **ә) *шагыйрь***
   б) *гомер*
   в) *каләм*

2. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Маңгае йолдызлы***
   **а) *бәхетле***
   ә) *гаепле*
   б) *яралы*
   в) *мактанчык*

3. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *бишек*
   **ә) *бишлек***
   б) *бишәү*
   в) *бишенче*

4. Асыл сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *урмандагы*
   ә) *күзге*
   б) *фәнни*
   **в) *сары***

5. Үтенүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *ләбаса*
   ә) *һич*
   **б) *-чы***
   в) *кына*

6. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Яхшы җырның даны **үзеннән** алда йөри.* (Мәкаль)

а) ия

**ә) тәмамлык**

б) урын хәле

в) аергыч

7. Икеләнүне белдерә торган кереш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) *мөгаен***

ә) *зинһар*

б) *билгеле*

в) *ичмасам*

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Тел әйтә алмаганны җыр әйтер.* (Мәкаль)

а) гади җөмлә

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

**в) иярченле кушма җөмлә**

9. Җөмләдәге иярчен компонентның төзелеше һәм мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кулың җиткән ботакның җимешен өз.* (Мәкаль)

а) синтетик тәмамлык җөмлә

ә) синтетик урын җөмлә

**б) синтетик аергыч җөмлә**

в) аналитик аергыч җөмлә

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә.* (Мәкаль)

а) 2

**ә) 3**

б) 4

в) 5

## II. Башыгызны эшләтегез.

*Коралда кырык кешенең көче бар. Эшләнеп бетмәгән эшнең бәясе тишекле бер тиен.* **(4 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Кадер сүзендә ике сузык аваз, **өч** тартык аваз бар. Сузык авазлары: [ә] һәм [э]. Ул сингармонизм законының рәт гармониясенә **буйсынган**. **Ике** иҗектән тора. Аңа **нечкә** кушымча ялгана. Ул – **гарәп/гарәп-фарсы** алынмасы. Синонимы – **хөрмәт,** ихтирам. Кадер – **исем** сүз төркеме. Кадер сүзеннән **парлы** исемнәр ясала.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

Мәсәлән: *Ул, мөгаен, элеккечә иртән печенье белән кәһвә эчәдер.*

*Агулы гөмбәне, һичшиксез/әлбәттә, ашарга яраклы гөмбә белән еш бутыйлар.*

*Ишекне ачтылар, һәм ишегалдыннан аш бүлмәсенә саф һава килеп керде.*

*Мин тәрәзәне ачкач, бүлмә канәфер чәчәгенең хуш исе белән тулды.*

2. Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

*Бервакыт Мәскәүдә, татарлар оештырган концерт барышында, залда* ***утырган*** *бер рус кешесенең сәхнәгә "Телегез искиткеч гүзәл, аның киләчәге зур,* ***мин*** *аны, һичшиксез, өйрәнәчәкмен"* ***дигән*** *язу җибәрүе хәтеремдә. Бу* ***кешегә*** *телебезнең милли моңыбызга үрелеп баруы тәэсир ясаган, күрәсең.*

*Тел* ***һәм*** *моң – милләт сакчылары. Тел бетсә, моң да калмый, милләт бетә. Балалар русча да, инглизчә дә, французча да, алманча да укысыннар. Тик менә шушы телләрнең, гомумән, белем-мәгърифәтнең ачкычы туган телебез икәнлеген онытмасыннар. Алар үсеп* ***буйга*** *җиткәч, җәмгыятьтә үз* ***урыннарын*** *алгач, "Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы" диярлек* ***булсыннар.*** (Индус Таһировтан)

2.1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(2 балл)**

*тәэсир* – **йогынты**, *алманча* – **немецча**

2.2. *Җәмгыятьтә* сүзенең транскрипциясен языгыз. **(2 балл)** [**җәмғиййәттә**]

2.3. Һәмзә тартыгы кулланылган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (тәэсир)**

2.4. Кушма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз. **(3 балл) (бервакыт, искиткеч, һичшиксез)**

3. Туган телегез сезнең өчен нәрсә ул? Сез аны нигә өйрәнәсез? Шул хакта 12 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**